РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Буа шәһәре

21.10.2021 № 314/ИК-п

Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында
хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, әлеге актларны
карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү тәртибенә
үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы «Сатып алулар өлкәсендә нормалар билгеләү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау турында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 21 июнендәге 712 номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә Буа муниципаль районының Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. ТР Буа муниципаль районының Башкарма комитетының 2017 елның 5 маендагы 176-п номерлы «Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, әлеге актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү тәртибенә гомуми таләпләрне раслау турында» карары белән расланган Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, әлеге актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү тәртибенә киләсе үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның г) пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Шакирҗанов